

Кадошкино районы Латышовка авылында гомер итvче Әминә Хәсән кызы Саитовага, 90 яшь тулу унаеннан, Президентыбыз В.В.Путин котлавы килгән. Ә котлауда – язмышыннан юллар.

Гади авыл кешесе язмышы. Әминә Хәсән кызына, Боек Ватан сугышы башлангач, унсигез яшь тула. Бу буын кешеләренә кvпне кvрергә, кvпкә чыдарга туры килә. Яшьли калганнар тылда да жафа житәрлек кvрә. Коне буе фронтка ипи vстерv, жыю, ә кичләре тагы хезмәт белән бергә vткән. Урманнан агачларны ой алдына китергәч, тvндәкләргә пила белән пилить итvләр, ә аннары чурка ярулар – барысы аларнын кичке хезмәт списогында була. Норманны vтәгәч кенә йокларга ятарга туры килгән. Иртән, топ хезмәткә киткәнче, шул чуркаларны арбага тояп озатканнар. Әминә Хәсән кызы истәлекләреннән. «Урман да кисәргә туры килде, - дип хәтер капчыгын сvтә ул. Кvпне кvрдек, безне жәлләvче булмады. Яшь башым белән атлар да карадым...      Сугыш тәмамланды, әмма безнен эш бетмәде. Латыштан, 37 кешелек бригада тозеп, Смоленщинага озаттылар. Эш кvп, ә сугыштан сонгы чорда эшләргә кеше аз, шуна торле яклардан жыелып эшләдек бу жирләрдә. Мин аш пешердем. Ә ойгә кайткач, фермабызда сыер савучы булып хезмәт юлымны дәвам иттердем. Шунда лаеклы ялга кадәр эшләдем. Шулай туган авылымда гомерләр эштә vтте, нәкъ Президентыбыз котлау хатында язганча.

Гаилә кордык, ирем – «алтын кеше» иде. Мин тормышым белән бик тә канәгать. Хезмәтчән һәм гади булды Зәкәрьям. Анын белән икәv дvрт бала тәрбияләп vстердек. Оныкчаларыбыз инде безне шатландыралар. Тормышка рәнжер хәлем юк. Шатлыклар һәм югалтулар очен рәхмәтлемен! Шуна ул тормыш диелә. Бvгенге яшәеш әйбәт; яшә һәм шатлан, ялкауланмый эшли генә бел. Лаеклы пенсия алабыз, вакытында китереп бирәләр.

Авылыбыз vсә, матурая, яшьләр кvп, мәктәбебез яхшы, яна ФАПыбыз. Һәрбер кешенен оенә суы кертелгән, газ белән ягыла; жылы, якты. Карт кешегә тагы ни кирәк! Тиздән сайлаулар, мин башланган эшләрнен унышлы тәмамлануы, тыныч тормыш очен тавышымны бирәчәкмен. Бvгенге Ватаныбызны кочле һәм бәйсез кvрәсе килә», - ди 90 яшен тутырган юбиляр Әминә Хәсән кызы Саитова.

Әминә Хәсән кызы матур йортта кызы Надия белән яши. Картлыгы ышанычлы кулларда. Уллары да еш әниләренен хәлен белергә киләләр. Бер сvз белән әйткәндә, авыр хезмәттә vткән гомере матур картлыкта уза.

«Әниемнен кvнеле һәрвакыт изге-лектә булды; барча кешегә һәм һәрбер нәрсәгә, - дип остәп куя Әминә Хәсән кызы Саитованын кызы Надия. – Мин белгәнчә, ул һәрвакыт

гаиләсе турында кайгыртты, гомере хезмәттә vтте. Без йокларга ятканда әле аяк остендә булды, иртән торганда – һаман аяк остә булуы хәтеремдә. Шуна да без Әниебезне кадер-хөрмәттә яшәтергә тиешбез. Лаеклы ялы рәхәттә vтсен. Безнен очен һәрвакыт янган йорәге тыныч булсын. Барыбызны шатландырып озак яшәсен иде кадерлебез!»
Кремльдан Латышовка авылы гади хатынына, Әминә Хәсән кызы Саитовага, 90 яшьлек юбилеена килгән котлауда шатлыклы озын гомер теләнгән иде.

**Н.Хәлил**